РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район, п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

23.10.2024г. №26

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Советының 09.03.2023 елгы №11 карары белән кабул ителгән муниципаль берәмлек Уставын "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 06.10.2003 елгы №131 Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын раслау турындагы 09.03.2023 елгы №11 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегендә җәмәгать тыңлауларын һәм җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 21.03.2023 елда №12 карары белән расланган тәртиптә ТР, Саба районы, Иштуган тимер юл разъезд бистәсе, Үзәк ур., 9 йорт адресы буенча урнашкан Иштуган мәдәният йортында 04.12.2024 көнне сәг. 09:00 ачык тыңлаулар үткәрергә.
4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 03.12.2024 елга кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Советына җибәрергә.
5. Махсус мәгълүмат стендларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турындагы карарны халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу

AnyScanner

һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен түбәндәге адреслар буенча бастырып чыгарырга:

- Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, тюрб.Иштуган, Үзәк ур., 11;
- Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, тюрб.Иштуган, Үзәк ур., 9.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Д.М.Гайнутдинов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 23.10.2024 елгы №26 карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты**

1. 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 21) пунктча өстәргә:
   «21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;
2. 19 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында»гы сүзләрен «1 – 7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;
3. 34 статьяның 1 пунктындагы 26) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «26) матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;
4. 41 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.1 пунктчасы өстәргә:
   «12.1) аның чит ил агенты статусын алуы;».

AnyScanner

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 23.10.2024 елгы №26 карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр язма рәвештә Иштуган авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422050, ТР, Саба муниципаль районы, тюрб.Иштуган, Үзәк ур., 11.

   Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында игълан ителгән яисә хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылган көннән алып кабул ителә.
2. Җәмәгать тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча шәхсән яки почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» тамгасы белән) бирелә: 422050, ТР, Саба муниципаль районы, тюрб.Иштуган, Үзәк ур., 11.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Д.М.Гайнутдинов